# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **03.12.2021**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чубар- Абдул авыл җирлеге составына кергән
Буралы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 03 декабрендә үткән гражданнар узган түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2022 елда, Чубар –Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- контейнер мәйданчыклары төзү (киртәләр өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, нигез салу, контейнерлар сатып алу);
- Җәлил, Октябрьская урамнары буенча гравияле өслекле юллар салу (сатып алу, йөртү, салу, юлларны грейдер белән тигезләү, контракт буенча эшләр өчен түләү.

«Әйе» «Юк».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 248 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 129 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 129 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Буралы авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2022 елда, Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- контейнер мәйданчыклары төзү (киртәләр өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, нигез салу, контейнерлар сатып алу);
- Җәлил, Октябрьская урамнары буенча гравияле өслекле юллар салу (сатып алу, йөртү, салу, юлларны грейдер белән тигезләү, контракт буенча эшләр өчен түләү кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрьская урамы, 34 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов